ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***
***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ***

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***
***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ***

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

14 сентябрь 2018 ел № 3-35

«Буа муниципаль районы Буа шәһәренең
Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында»

Буа муниципаль районының архитектура бүлеге башлыгының Буа шәһәр Советының 2011 елның 9 августындагы 2-9 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районының җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Буа муниципаль районының җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссия бәяләмәсен исәпкә алып, Буа шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Ипподром ур., (кадастр номеры 16:14:000000:1287) адресы буенча урнашкан территорияне үзгәртү өлешендә, Индивидуаль торак йортлар белән төзелеш зонасы – Ж1 зонасыннан Индивидуаль торак йортлар белән төзелеш зонасы - Ж1 зонасына үзгәртеп, Буа муниципаль районы Буа шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә (кушымта).

2. Жорес ур., 39/44 (кадастр номеры 16:14:990145:304) адресы буенча урнашкан территорияне үзгәртү өлешендә, Спорт-тамаша һәм физкультура-савыктыру корылмалары зонасы – Р2 зонасыннан Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерциягә билгеләнгән зона - Д1 зонасына үзгәртеп, Буа муниципаль районы Буа шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә (кушымта).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Буа шәһәре башлыгы М. А. Җәббаров